| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«НИЖНЕЧЕРШИЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ТҮБӘН ЧЫРШЫЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2022 елның 19 декабре №31

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районыннан җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 3 өлеше, 15 статьясы, Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегеннән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү өлешендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны, алга таба Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органы тарафыннан раслануга чыгарып, кабул итәргә.

2. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органы тарафыннан раслануга чыгарылып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшкәртү, үзгәрешләр кертү өлешендә эшне оештырырга,

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Түбән Чыршылы авылы, Түбән Чыршылы авылы административ бинасында-Үзәк урам, 105 йорт, балалар бакчасы бинасында -Совет урамы, 8 йорт, Үзәк урам, 23 йорт буенча, ФАП бинасында-Мельничная урамы, 23 йорт, Мордва Ивановка авылында-авыл клубы бинасында-Горная урамы, 27 йорт, Мордва Ивановка авылында Совет урамы, 13 йорт буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Н.Я.Хәйруллина